КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 сентябрь г.Казань № 1029

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы; 2018 ел, 7 май, 327 нче; 2018 ел, 30 июль, 614 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче; 2019 ел, 23 апрель, 329 нчы; 2019 ел, 18 декабрь, 1165 нче; 2020 ел, 11 февраль, 87 нче; 2020 ел, 15 май, 392 нче; 2020 ел, 8 август, 666 нчы; 2021 ел, 17 июнь, 467 нче; 2021 ел, 11 август, 700 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче; 2021 ел, 27 ноябрь, 1140 нчы; 2021 ел, 9 декабрь, 1209 нчы; 2022 ел, 7 март, 202 нче; 2022 ел, 17 март, 244 нче; 2022 ел, 29 апрель, 402 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктның алтынчы абзацына «(01.06.12*)» саннарын өстәргә;

4.2 пунктта:

4.2.2[1] пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.2[1]. «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә һәм очракларда

документларны (алардагы мәгълүматларны) «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенә җибәрә, шул исәптән Татарстан Республикасы Президентының махсус сакланыла торган төбәк әһәмиятендәге табигать территориясенең сакланыла торган зонасын билгеләү, үзгәртү яки аның гамәлдә булуын туктату турындагы; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының махсус сакланыла торган төбәк әһәмиятендәге табигать территориясе чикләрен билгеләү яки үзгәртү турындагы, махсус сакланыла торган төбәк әһәмиятендәге табигать территориясе турындагы нигезләмәне раслау хакындагы яки әлеге нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турындагы актлары нигезендә мәгълүматларны Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертүгә юнәлдерелгән гамәлләрне башкара, әлеге электрон документларны, шул исәптән XML-документларны көчәйтелгән квалификацияләнгән электрон имза белән раслый;»;

4.2.4 пунктта «махсус сакланыла торган табигать территорияләре турындагы законнарны бозу аркасында» сүзләрен «мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында махсус сакланыла торган табигать территорияләренә» сүзләренә алмаштырырга;

4.2.12 пунктта «үсемлекләр дөньясы объектларын саклау өлкәсендәге законнарны бозу аркасында үсемлекләр дөньясы объектларына салынган» сүзләрен «мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында үсемлекләр дөньясы объектларына салынган» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле $5.1^{13}$ пунктча өстәргә:

«$5.1^{13}$. Мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында махсус сакланыла торган табигать территорияләренә салынган зыянны каплау турындагы дәгъва буенча бәяләмә бирү өчен суд тарафыннан делода катнашуга җәлеп ителергә яисә үз инициативасы белән делога керергә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин